ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ПО БИОЛОГИЧЕСКИМ РЕСУРСАМ
ул. Карима Тинчурина, д. 29, г. Казань, 420021

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫ БИОЛОГИК
РЕСУРСЛАР БУЕНЧА
ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ
К. Тинчурин ур., 29 йорт, Казан шәһәре, 420021

Телефон:(843)211-66-94, факс:(843)211-66-47, E-Mail:ojm@tatar.ru, сайт:http://ojm.tatarstan.ru

Приказ г.Казань Боерык

22.04.2020 № 125- од

Татарстан Республикасы Биологик ресурслар буенча дәүләт комитетының 2018 елның 7 нче июненнән 145-од номерлы боерыгы белән расланган, Татарстан Республикасының региональ әһәмияттәге аерым саклана торган табигый тыюлык территориясе чикләрендә төзелгән, реконструкцияләнгән капиталь төзелеш объектын файдалануга кертү өчен рөхсәтнамәләр бирү буенча дәүләт хезмәтен күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына үзгәрешләр кертү белән бәйле рәвештә боерам:

1. Татарстан Республикасы Биологик ресурслар буенча дәүләт комитетының 2018 елның 7 нче июненнән 145-од номерлы боерыгы белән расланган, Татарстан Республикасының региональ әһәмияттәге аерым саклана торган табигый тыюлык территориясе чикләрендә төзелгән, реконструкцияләнгән капиталь төзелеш объектын файдалануга кертү өчен рөхсәтнамәләр бирү буенча дәүләт хезмәтен күрсәтүнең административ регламентына (Татарстан Республикасының Биологик ресурслар буенча дәүләт комитетының 14.11.2018 ел, № 344-од, 12.12.2019 ел, № 392-од боерыклары белән кертелгән үзгәрешләр белән) ( алга таба – Регламент) киләсе үзгәрешләрне кертергә:

1 бүлекнең 1.3.2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе һәм аның башкарылуы турында белешмәләр Биотөрлелек бүлеге (алга таба - Бүлек) тарафыннан (843) 211-68-62 телефоны буенча бирелә.»;

1 нче бүлекнең 1.3.4 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Дәүләт хезмәте, шулай ук Комитетның урнашу урыны һәм эш графигы турында мәгълүмат түбәндәге ысуллар белән алынырга мөмкин:

1) «Интернет» челтәре аша:

Комитетның рәсми сайтында (http://ojm.tatarstan.ru);

Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында (http://uslugi.tatarstan.ru);

Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләр) бердәм порталында (http://gosuslugi.ru);

2) Комитетка телдән мөрәҗәгать иткәндә:

шәхсән (102 нче кабинет);

телефон буенча ((843) 211- 68 - 62);

3) Комитетка язмача мөрәҗәгать иткәндә (шул исәптән электрон документ формасында рәсми почтага ojm@tatar.ru);

4) мөрәҗәгать итүчеләр белән эшләү өчен, Комитетның биналарында урнашкан дәүләт хезмәте турында визуаль һәм текст мәгълүматын үз эченә алган дәүләт хезмәте турында мәгълүмати стендлар аша»;

2 бүлектәге 2.5 пунктының «Стандартка куелган таләпләр эчтәлеге» графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Объектны файдалануга кертү өчен рөхсәт бирү турында гариза.

Объектны файдалануга кертү өчен рөхсәт бирү турындагы гаризага түбәндәге документларны беркетергә кирәк:

1) капиталь төзелеш объектын кабул итү акты (төзелеш, реконструкцияләүне гамәлгә ашыру очрагында, төзелеш подряды килешүе нигезендә);

2) төзелгән, реконструкцияләнгән капиталь төзелеш объектының параметрларының проект документларына, шул санда энергетика нәтиҗәлелеге таләпләренә һәм файдаланыла торган энергетик ресурсларны исәпкә алу приборлары белән җиһазлану таләпләренә туры килүен раслый торган һәм төзүне гамәлгә ашыручы зат тарафыннан (төзелешне гамәлгә ашыручы, төзү подряды килешүе нигезендә төзелешне, реконструкцияне гамәлгә ашырган очракта, төзүче яки техник заказчы, шулай ук төзелеш контроле шартнамәсе нигезендә төзелеш контролен гамәлгә ашыручы зат тарафыннан ) имзаланган акт.

3) төзелгән, реконструкцияләнгән капиталь төзелеш объектының техник шартларга туры килүен раслаучы һәм инженер-техник тәэмин итү челтәрләрен эксплуатацияләүне гамәлгә ашыручы оешма вәкилләре (алар булганда) кул куйган документлар;

4) төзелгән, реконструкцияләнгән линияле объекттан кала, җир бүлемтеге чикләрендә төзелгән, реконструкцияләнгән капиталь төзелеш объектының, инженер-техник тәэмин итүче челтәрләрнең урнашуын һәм җир бүлемтегенең планлы оешмасын чагылдыра торган һәм төзүне гамәлгә ашыручы зат тарафыннан (төзелешне гамәлгә ашыручы, төзү подряды килешүе нигезендә төзелешне, реконструкцияне гамәлгә ашырган очракта, төзүче яки техник заказчы, шулай ук төзелеш контроле шартнамәсе нигезендә төзелеш контролен гамәлгә ашыручы зат тарафыннан ) имзаланган схема;

5) куркыныч объектта һәлакәт нәтиҗәсендә зыян китерү өчен, куркыныч объект хуҗасының гражданлык җаваплылыгын мәҗбүри иминләштерү турында Россия Федерациясе кануннары белән тәңгәл килеп, куркыныч объектта һәлакәт нәтиҗәсендә зыян китерү өчен, куркыныч объект хуҗасының гражданлык җаваплылыгын мәҗбүри иминләштерү шартнамәсен төзүне раслаучы документ;

6) әлеге объектны реставрацияләү, консервацияләү, ремонтлау һәм аны заманча куллану өчен уңайлы иткән вакытта, 25.06.2002 елдан 73-ФЗ "Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарих һәм мирас һәйкәлләре) турында"гы Федераль канун белән билгеләнгән, туры килүче мәдәни мирас объектларын саклау әгъзасы белән расланган, мәдәни мирас объектын саклап калу буенча башкарылган эшләрне кабул итү акты;

7) 13.07.2015 елдан 218-ФЗ номерлы "Күчемсез милекне дәүләт теркәве турында"гы Федераль канун белән тәңгәл килеп әзерләнгән, капиталь төзелеш объектының техник планы.

Әлеге пунктның 1-4 пунктчаларында күрсәтелгән документлар, әгәр күрсәтелгән документлар (аларның күчермәләре яки аларда булган белешмәләр) дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары яисә дәүләт органнары яисә җирле үзидарә органнары карамагында булмаса,гариза биръче тарафыннан мөстәкыйль җибәрелә. Әгәр әлеге өлештә күрсәтелгән документлар дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары яки дәүләт органнары яки җирле үзидарә органнары карамагында булса, мондый документлар Комитет тарафыннан әлеге документлар карамагында булган органнардан һәм оешмалардан соратып алына, әгәр төзүче күрсәтелгән документларны мөстәкыйль рәвештә тапшырмаган булса.

Әгәр төзелеш этабына карата һәм капиталь төзелеш объектына карата объектны файдалануга тапшыруга рөхсәт бирү турында гариза бирелгән очракта, әлеге пунктта күрсәтелгән документлар капиталь төзелеш объектын төзү, реконструкцияләүнең тиешле этабына кагыла торган өлешендә бирелә. Күрсәтелгән очракта капиталь төзелеш объектын төзү, реконструкцияләү этабына карата объектны файдалануга тапшыруга рөхсәт бирү турындагы гаризада капиталь төзелеш объектын төзү, реконструкцияләү этабына карата (булганда) объектны файдалануга тапшыруга элегрәк бирелгән рөхсәтләр турында белешмәләр күрсәтелә.

Объектны файдалануга тапшыруга рөхсәтнамә, объектны файдалануга тапшыруга рөхсәт бирү турында гаризада күрсәтелгән очракта, электрон имза белән имзаланган электрон документ рәвешендә бирелә.

Дәүләт хезмәте алу өчен гариза бланкын, гариза бирүче Комитетка шәхси мөрәҗәгать иткәндә алырга мөмкин. Бланкның электрон формасы Комитетның рәсми сайтында урнаштырылган.

Гариза һәм кушып бирелә торган документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан кәгазьдә түбәндәге ысулларның берсе белән тапшырылырга (җибәрелергә) мөмкин:

шәхсән (мөрәҗәгать итүче исеменнән эш итүче зат тарафыннан ышанычнамә

нигезендә);

почта аша.

Мөрәҗәгать итүче «Татарстан Республикасы Электрон Хөкүмәте» дәүләт мәгълүмат системасы аша, гомуми файдаланудагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләре аша, шул исәптән «Интернет»мәгълүмат-телекоммуникация челтәре аша, көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган электрон документ рәвешендә гариза һәм документларны тапшырырга (җибәрергә) хокуклы.»;

Регламентның 1 нче кушымтасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасының региональ әһәмияттәге аерым саклана торган табигый тыюлык территориясе чикләрендә төзелгән, реконструкцияләнгән капиталь төзелеш объектын файдалануга кертү өчен рөхсәтнамәләр бирү буенча дәүләт хезмәтен күрсәтүнең административ регламентына 1нче кушымта.

кемгә: Татарстан Республикасы Биологик ресурслар буенча дәүләт комитетына

кемнән: ________________________________________

(юридик затның исеме - объектны

________________________________________

файдалануга кертергә җыена торган йөрт төзүче;

________________________________________

ИНН; юридик һәм почта адресы,

________________________________________

җитәкченең исеме,фамилиясе, атасының исеме;

________________________________________

телефон; банк реквизитлары (банкның исеме,

________________________________________

р/с, к/с, БИК)

**Объектны файдалануга кертү өчен рөхсәтнамә бирү турында гариза.**

________________________________________________________________

(шәһәр, район, урам, бүлемтек номеры)

адрес буенча җир бүлемтегендә төзелгән\реконструкцияләнгән (

төзү\реконструкция этабы)

_____________________________________________________________

(объектның исеме)

капиталь төзелеш  объектын файдалануга кертү өчен рөхсәтнамә бирүегезне сорыйм.

Төзелеш\реконструкция_____________________________________

(документ исеме)

«______» ________ елдан № ________ нигезендә,  тулы күләмдә тормышка ашырылды,  төзелеш\реконструкция этабы __________________________________

( кирәклесенең астына сызарга)

___________________________________________________________________

(төзелеш\реконструкция этабын күрсәтергә, аның кыскача характеристикасы)

___________________________________________________________________

______________________________________________________________________.

Җир белән куллану хокукы ________________________

«______»_________ елдан  № ____________________________________ белән беркетелгән. (документ исеме)

Өстәмә хәбәр итәбез:

Йорт төзүче белән төзелешне\реконструкцияне (төзелеш\реконструкция этабын) түләүгә финанслар бүлеп чыгарылды._____________________________

(банк реквизитлары һәм счет номеры )

Эшләр «______» ______________________ г. № ________,килешүнамә нигезендә подрядчы (хуҗалык)ысулы белән  алып барылдылар ______________

_________________________________________________________________

(Оешманың исеме, ИНН; юридик һәм почта адресы,

_________________________________________________________________

җитәкченең исеме,фамилиясе, атасының исеме; телефон; банк реквизитлары (банкның

_________________________________________________________________

исеме,р/с, к/с, БИК)

Төзү-монтаж эшләрен  үтәү хокукы беркетелгән ___________________________

_____________________________________________________________________

(документның һәм аны биргән вәкаләтле әгъзаның исеме)

__________________________________ «______» _________елдан № _______.

Эшләрне җитештерүче белән ____________________________ «_____» _________________ елдан № _______  боерык белән

махсус ______________белеме  һәм төзүдә _________ ел эш стажы булган

( югары, урта)

______________________________________________________________ билгеләнде.
(вазыйфа, фамилия, исем, атасының исеме)

Төзелешне тикшерү «______» _________елдан № _______ килешүнамә белән тәңгәл килеп,________________________________________________________

____________________________________________________________________
(Оешманың исеме, ИНН; юридик һәм почта адресы,
____________________________________________________________________
җитәкченең исеме,фамилиясе, атасының исеме; телефон; банк реквизитлары (банкның
____________________________________________________________________
исеме,р/с, к/с, БИК)

белән башкарылды.

Заказ бирүченең ( йорт төзүченең)  функцияләрен үтәү хокукы
_________________________________________________________________________
(документның һәм аны биргән вәкаләтле әгъзаның исеме)

«_____» _________________ елдан № _______  нигезендә беркетелде.

Әлеге гаризада күрсәтелгән барлык мәгълүматлар белән бәйле үзгәрешләр турында, ____________________________________________________________
(вәкаләтле әгъзаның исеме)

хәбәр итәргә вәгъдә бирәм.

_________________ ________________ __________________________________

(вазыйфа) (имза) (Ф.И.О.)

«______» _______________________ ел

П.У.».

2. Рәис урынбасарларына, структур бүлекчә җитәкчеләренә, дәүләт хезмәте күрсәтүне турыдан-туры тәэмин итүче затларга Регламент нигезләмәләрен үтәүне һәм алар тарафыннан каралган документларны алып баруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге боерык рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә дип танырга.

Рәис Ф.С.Батков